ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 037 от «25» 02 2021 г.

2017 елның 9 сентябрендәге 092 нче
карары белән расланган Татарстан
Республикасы Мамадыш муниципаль
районы территориясендә гадәттән тыш
хәлләрдә һәм сугыш вакытында оешмаларның
тотрыклы эшләвен арттыру буенча Комиссия
турында Нигезләмәгә үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 21.12.1994 елның 21 декабрендәге №68-ФЗ Федераль закон, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге №28-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Указом Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2008 года №УП-598 «Об утверждении Положения об организации об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан», «Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларның сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә тотрыклы эшләвен арттыру комиссиясен төзү турында» 2017 елның 11 июлендәге 473 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, шулай ук хәрби конфликтларда яки, шул конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның исән калу өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. 2017 елның 9 сентябрендәге 092 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрдә һәм сугыш вакытында оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча Комиссия төзү турында Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 4.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: Комиссия утырышлары комиссия рәисе раслаган эш планы нигезендә елга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә үткәрелә. Комиссия карарлары утырышта катнашканнарның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. «Риза» һәм «каршы» тавышлары тигез булган очракта, рәислек итүче

000048

тавышы хәлиткеч булып тора. Комиссия секретаре комиссия утырышы беркетмәсен алып бара, анда аның карары һәм тавыш бирү нәтиҗәләре теркәлә, беркетмәгә рәислек итүче һәм секретарь тарафыннан комиссия утырышы уздырылган көнне имза куела.

2. Муниципаль берәмлекләр башлыкларына һәм Мамадыш муниципаль районы оешмалары җитәкчеләренә сугыш вакытында һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район
Башлыгы

А.П. Иванов